Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Укытучылар өчен методик кулланма




# 8

«Татармультфильм»

Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 8 нче сыйныф

**Укытучылар өчен методик кулланма**

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителә*

Казан
2025

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)
Х18

Фәнни редакторы
**Р.З. Хәйдәрова**, педагогика фәннәре кандидаты, доцент

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всего издания или его части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хайдарова, Р. З. и др.**
Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 8 класс: : методическое пособие для учителя к учебнику для общеобразовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина. – Казань: Татармультфильм, 2025. – 44 с.

ISBN 978-5-906508-50-8

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)

ISBN 978-5-906508-50-8

© «Татармультфильм» нәшрияты, 2025
© Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М., Гыйниятуллина Л.Ә., 2025

**8 нче сыйныфта «Татарстан Республикасы дәүләт (татар) теле» фәнен укыту өчен төзелгән укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре**

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – **системалы-эшчәнлекле юнәлеш (системно-деятельностный подход)**, ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик күрсәтмә рус телле балаларга татар теле укыту системасын оештыруның да нигезе булып тора.

Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар телен дәүләт теле буларак укытуның төп максаты – укучыларның рухи һәм әхлакый үсешен тәэмин итү, аларның күпмилләтле җәмгыятьтә милләтара мөнәсәбәт культурасын формалаштыру, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыру. Шулай ук татар телен дәүләт теле буларак укыту телне **аралашу** чарасы буларак үзләштерүне тәэмин итү, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә **үзара аңлашу** һәм **хезмәттәшлек** итү күнекмәләрен формалаштыру. Шулай ук укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү; уку эшчәнлеген оештыруның нигезе булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, аларны мөстәкыйль уку эшчәнлегенә әзерләү.

Татарстан Республикасы мәктәпләре өчен төп гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен укытуга **372 сәгать** вакыт бирелә. Базис укыту планында 8 нче сыйныфта атнага 3 сәгать исәбеннән **102 сәгать** каралган.

Сигезенче сыйныфта укучы рус телле балаларга тәкъдим ителгән укыту-методик комплекты (УМК) түбәндәге компонентлардан тора:

1. Дәреслек.
2. Укытучы өчен методик ярдәмлек:
   – календарь-тематик план;
   – ишетеп аңлау күнегүләре;
   – контроль-үлчәм материаллары.

УМКга эчтәлек сайлау Россия мәгариф министрлыгының 18.05.2023 елгы 372 номерлы «Төп гомуми белем бирүнең федераль белем бирү программасын раслау турында»гы боерыгына (теркәлү вакыты: 12.07.2023 ел, №74229) һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына нигезләнде**.**

**Телне аралашу аша өйрәнү принцибы** нигезендә УМК өчен материал укучыларның яшь үзенчәлекләреннән, теләк-омтылышларыннан, аралашу ихтыяҗларыннан чыгып сайланды.

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: «Күп укыган күп белер», «Яшьтәшләр белән аралашу», «Спорт – сәламәтлек чыганагы», «Туган илем шәһәрләре һәм истәлекле урыннар», «Музыка дөньясында», «Табигать һәм кеше». Тематик планнарда темаларның эчтәлеге киңәйтелеп, федераль эш программасына тәңгәллеге күрсәтелеп барылды.

Федераль эш программасына нигезләнеп, дәреслеккә грамматик материал түбәндәгечә кертелде:

– ясалма, парлы, кушма, тезмә исемнәр;

– ясалма, кушма исемнәр, сыйфатлар;

– исем + тартымлы исем төзелмәсе: *Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре;*

– билгесезлек алмашлыклары: *кемдер, әллә кем;*

– күләм-чама рәвешләре: *еш, сирәк;*

– инфинитив + модаль сүзләр: *кирәк / кирәкми, ярый / ярамый, мөмкин / мөмкин түгел, тиеш / тиеш түгел*;

– хәл фигыльнең 1 нче төре: *-ып/-еп/-п*;

– эшнең башлануын һәм тәмамлануын белдерүче аналитик фигыльләр *укый башлады, укып бетерде*;

– хәзерге (*баручы кеше, бара торган поезд*) һәм үткән заман сыйфат фигыль (*килгән кунак*);

– исем фигыль + *өчен* бәйлеге (*белү өчен*);

– җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре;

– *беренчедән, икенчедән, өченчедән* кереш сүзләре;

– *да / дә, та / тә, яки* теркәгечләре;

– *менә, бит, тагын* кисәкчәләре;

– кушма җөмләләрдә сүз тәртибе.

Күрсәтелгән эчтәлектән тыш, алдагы сыйныфларда өйрәнелгән лексик-грамматик материал даими рәвештә кабатланып барылды.

Рус телле балаларны татар сөйләменә коммуникатив технология нигезендә өйрәтү **дәреслекләренең төзелеше цикллылыкка** корылган. **Цикл – уку материалын диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр.** Ягъни өйрәнелгән лексик-грамматик материал, тану дәрәҗәсендә генә калмыйча, сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерелергә тиеш. Дәрес тибы буенча

бу дәресләр текст алды дәресләре: **лексик күнекмәләр формалаштыру** (ЛКФ) **һәм грамматик күнекмәләр формалаштыру** (ГКФ); **текст өстендә эш дәресләре: лексик, грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре** (ЛГКК), **диалогик/монологик сөйләм дәресләре** (Д/МС) дип атала. Бу дәресләр циклында өйрәнелгән лексика һәм грамматика туры-дан-туры текстта кабатлана, төрле бәйләнешләргә керә, ягъни лингвистик материалны сөйләмдә куллану камилләшә. Тексттан соң булган этапта текст эчтәлеге буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу дәресләре оештырыла, укучылар материал эчтәлеге буенча спонтан сөйләм – татарча аралашу этабына чыгалар.

Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнүдә күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Шуңа күрә дәреслектә эчтәлекне мөстәкыйль сөйләмгә җиткерү өчен сөйләми (речевые) күнегүләр: диалоглар, ситуатив күнегүләр, иҗади биремнәр еш кулланылды. Дәреслектәге күнегүләрдән тыш, укытучылар түбәндәге методик ярдәмлеккә мөрәҗәгать итә алалар: «Мин татарча сөйләшәм. Я говорю по-татарски». Сборник ситуативных упражнений для русскоязычных учащихся. Авт.: Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова, Л. А. Гиниятуллина. Наб. Челны, 2019.

Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуы тәэмин ителә.

Укучыларның сөйләми активлыгын булдыруда шулай ук уку эшчәнлеген оештыруның **эш режимнарын** дөрес оештыру да бик мөһим. Дәреслектә Федераль Дәүләт стандартларының таләпләренә туры килгән **парларда, төркемнәрдә, индивидуаль эшләү өчен биремнәр** һәм **иҗади биремнәр киң урын алды.** Алар дәреслектә аерым шартлы билгеләр белән күрсәтелә бардылар.

Укытучы өчен **методик ярдәмлеккә** ишетеп аңлау күнегүләре (аудирование), федераль эш программасы нигезендә төзелгән календарь-тематик план, һәр тема буенча контроль һәм үзконтроль материаллары кертелде.

1) **Ишетеп аңлау күнегүләре** – һәр дәрестә, дәреснең төрле этапларында кулланылырга тиешле сөйләм эшчәнлеге. Ишетеп аңлау күнегүләренә таләпләр федераль эш программасында киң яктыртылу сәбәпле, методик

ярдәмлектә дәрес темалары буенча күнегүләрнең үзләрен биру белән чикләнде.

2) Тәкъдим ителгән **тематик план** ел дәвамында өйрәнәсе материалның дәресләргә бүленешен күрсәтә. Һәр дәреснең коммуникатив максаты тематик планда аерым графада күрсәтелә барды, шуңа күрә дәрес планы, дәреснең структур этапларын планлаштырганда, аңа игътибар итү аеруча мөһим.

Федераль эш программасы бүлекләренең эчтәлеге тулысынча дәреслеккә һәм тематик планга салынды, аның үтәлеше күрсәтелә барды. Федераль эш программасы бүлекләренең эзлеклелеге белән дәреслектәге, тематик пландагы эчтәлек бирелеше эзлеклелеге тәңгәл килмәгән очракта да, **дәреслектәге һәм тематик пландагы дәресләр бирелешенең эзлеклелеген алыштырырга тәкъдим ителми**, чөнки федераль эш программасы нигезендә төзелгән дәреслек эчтәлегенең узара бәйләнеше, системалылыгы бозыла.

3) Укыту процессының уңышлылыгына тәэсир итә торган әһәмиятле факторларның берсе – ул укучыларның белемен **контрольгә** алу. Билгеле булганча, контроль укыту барышын көйли, ягъни контрольгә карап, укытучы үз эшчәнлеген оештыра. Методика фәне билгеләгәнчә, укучыларның ятлаганны сөйли белүләре, аерым сүзләрне, җөмләләрне тәрҗемә итә белүләре яисә грамматик категорияләрне аңлый алулары гына **контроль объекты** була алмый. Контрольнең төп объекты булып, укучының өйрәнелгән лексиканы һәм грамматиканы кулланып, **мөстәкыйль аралаша алуы** тора. Календарь-тематик планның коммуникатив максат графасында дәресләр өчен күрсәтелгән **предмет нәтиҗәләре, ягъни тема буенча сөйләшә белү күләме** укучыларның белем дәрәҗәләрен контрольгә һәм үзконтрольгә алуның да эчтәлеге булып тора ала. Дәрес планнары төзегәндә, дәреснең структур этапларын планлаштырганда, бу графага игътибар итү аеруча мөһим.

## Календарь-тематик план

| Дәрес номеры | Дәрес темасы | Дәреснең коммуникатив максаты |
|---|---|---|
| **Күп укыган күп белер (30 сәгать)<br>II. Мир вокруг меня** | | |
| 1–2 | Мәктәптә укулар башланды. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше.<br>Хикәя һәм сорау җөмләләрдә сүз тәртибе | Укытучыларны, иптәшләреңне Белем көне белән котлый белү. Тартымлы исемнәрне сөйләмдә дөрес куллану. «Мәктәбем» шигырен сәнгатьле уку; мәктәбең турында сөйли белү |
| 3–4 | Атна көннәрендә дәресләр расписаниесе.<br>Хикәя фигыльнең 3 заман формасы | Атна көннәре атамаларын кулланып, нишләгәнеңне, нишләячәгеңне, расписание буенча нинди фәннәр кирәчәген сөйли белү. Хикәя фигыльнең заман формаларын дөрес кулланып, беренче сентябрь турында сөйли белү |
| 5–6 | Ш. Галиев. «Безнең йорт малайлары» | Шигырьне сәнгатьле уку, эчтәлеге буенча диалоглар төзү |
| 7–8 | Билгесез үткән заман хикәя фигыль.<br>Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше | Үткән заман хикәя фигыльнең билгеле һәм билгесез төрләрен аера, җөмлә эчендә билгели белү. Билгесез үткән заман хикәя фигыльне зат-сан белән төрләндерә белү |
| 9–10 | Билгеле һәм билгесез киләчәк заман хикәя фигыль. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше | Киләчәк заман хикәя фигыльнең билгеле һәм билгесез төрләрен аера, җөмлә эчендә билгели белү, сөйләмдә урынлы куллану |
| 11–13 | В. Нуриевнең «Өлгерәм әле...» хикәясе (беренче өлеш).<br>Хәл фигыль.<br>Эшнең башлануын һәм тәмамлануын белдерүче аналитик фигыльләр | Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлеген кыскача сөйли белү.<br>Хәл фигыльле җөмләләрне аңлап уку, сөйләмдә куллану |
| 14–15 | Шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Шарт фигыльле җөмләләр | Шарт фигыльле җөмләләрне рус телендәге кулланылышы белән чагыштырып өйрәнү, сөйләмдә куллану |

| | | |
|---|---|---|
| 16–17 | «Өлгерәм әле» хикәясе (икенче өлеш).<br>Инфинитив + модаль сүзләр | Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлеген кыскача сөйли белү.<br>Җөмлә төзелешендә фигыльнең инфинитив формасын рус телендәге кулланылышы белән чагыштырырга өйрәнү, сөйләмдә дөрес куллану |
| 18–20 | «Өлгерәм әле...» хикәясе (өченче өлеш).<br>Геройга характеристика.<br>Ясалма, тезмә сыйфатлар | Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлеген кыскача сөйли белү.<br>Төп геройны характерлый белү.<br>«Син үз вакытыңны планлаштыра беләсеңме?» проблемасы буенча сөйләшү |
| 21–22 | Р. Вәлиеваның «Барый телевизор карый» шигыре.<br>Геройга характеристика | «Өлгерәм әле...» хикәясен үзгәртеп язу.<br>Шигырьне сәнгатьле уку, эчтәлеге буенча диалоглар төзү. Шигырьдәге геройны «Өлгерәм әле...» хикәясендәге герой белән чагыштырып сөйли белү |
| 23–26 | Мөхәммәт Мәһдиевнең «Рус теле дәресендә» хикәясе.<br>Татар телендә җөмлә төзелеше | Текстны аңлап уку, кирәкле мәгълүматны таба белү. Икенче телне өйрәнүдә тырышлык кирәклеге проблемасы, ике телне белү җиңел түгеллеге турында сөйләшү |
| 27–28 | Фәнис Яруллинның тормыш юлы, «Ялкау ялы» шигыре | Шигырьне сәнгатьле уку, эчтәлеге буенча диалоглар төзү, фикер алышу |
| 29–30 | Яхшы уку җиңелме?<br>Вакытны дөрес планлаштыра беләсеңме?<br>*Исем фигыль + өчен* төзелмәсе | Яхшы уку өчен нинди сыйфатлар кирәклеге турында, «Уку – энә белән кое казу» проблемасы буенча сөйләшү |
| **Яшьтәшләр белән аралашу (22 сәгать)<br>I. Мир моего «Я»** | | |
| 31–32 | Аралашу кагыйдәләре.<br>«Гаеп кемдә» тексты? | Аралашуның төп кагыйдәләрен сөйли белү.<br>Яшьтәшләрнең характер сыйфатларын сурәтләп сөйли белергә өйрәнү |
| 33–36 | «Аралашу серләре» тексты.<br>Кереш сүзләр | «Аралашу серләре» текстын аңлап уку.<br>Хат авторының сораулары буенча фикер алышуда катнашу; фикер белдергәндә, кереш сүзләр куллану |
| 37–39 | Әдәп төбе – матур гадәт.<br>Үз фикереңне ничек белдерергә?<br>Билгесезлек алмашлыклары | Әдәп кагыйдәләрен сөйли белү.<br>Текстны аңлап уку, бирелгән фикерләр белән килешүеңне яисә килешмәвеңне әйтә һәм дәлилли белү.<br>Тормыштан алынган ситуацияләр буенча сөйләшә белү, киңәшләр бирү |

| | | |
|---|---|---|
| 40–44 | М. Галиевнең «Җиңәсем килде» хикәясе.<br>Сыйфат фигыльнең заман формалары.<br>Без хикәя сөйлибез.<br>Илгиз – ул нинди образ? | Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлеген кыскача сөйли белү.<br>«Илгиз киләчәктә алдашу юлына басармы?» проблемасы буенча сөйләшү. Илгизнең уңай, тискәре сыйфатлары буенча сөйләшү |
| 45–47 | Ал кирәк, гөл кирәк, безгә нинди кыз кирәк?<br>Ясалма һәм тезмә сыйфатлар | «Безгә нинди кызлар ошый?» проблемасы буенча сөйләшү.<br>Төрле фикерләр белән килешүеңне яисә килешмәвеңне әйтә белү.<br>Ашарга пешерү тәртибен сөйли белү |
| 48–50 | Билгеләү алмашлыклары.<br>Минем төс – яшел. Ә синеке? | Билгеләү алмашлыкларын тану, тәрҗемәләрен һәм ике телдә дә кулланылыш үзенчәлекләрен белү; сөйләмдә дөрес куллану.<br>Үзеңә нинди төс ошаганны яисә нинди төстәге киемнәр килешкәнен әйтә белү; дусларыңа комплиментлар әйтү.<br>Дус кызлар (егетләр), апа-абыйларның тышкы кыяфәтләрен, аларга ничә яшь икәнен әйтә, характер сыйфатларын сурәтли белү |
| 51–52 | Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре.<br>Буш вакыт – ул нинди вакыт? | Җөмләнең баш кисәкләрен билгели белү.<br>«Буш вакытны файдалы, файдасыз үткәрү» проблемасы буенча сөйләшә белү |
| | **Спорт – сәламәтлек чыганагы (6 сәгать)**<br>**III. Мир моих увлечений** | |
| 53–54 | Сәламәт яшәү кагыйдәләре.<br>Күләм-чама рәвешләре (*еш, сирәк*) | Спорт – сәламәтлек чыганагы булуы турында сөйләшү. Сәламәт булу өчен киңәшләр бирә белү |
| 55 | Файдалы җиде ризык.<br>Исемнәрнең ясалышы буенча төрләре | Татарстанда үскән җиләк-җимеш, яшелчәләрнең организмга файдасы турында сөйли белү. Аларны кулланырга кирәклеген раслап, киңәш бирә белү |
| 56–58 | Казан – спорт шәһәре.<br>Казанда ял итү урыннары.<br>Гади җөмлә төрләре | Казанда спорт үсеше, ял итү урыннары турында сөйләшү |
| | **Туган илем шәһәрләре һәм истәлекле урыннар (19 сәгать)**<br>**IV. Моя Родина** | |
| 59–61 | Башкалабыз Мәскәү. Данлыклы Санкт-Петербург шәһәре | Башкалабыз Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре турында кыскача сөйли белү, диалоглар төзү |

| | | |
|---|---|---|
| 62–65 | Россиянең иң матур шәһәрләре, аларның истәлекле урыннары | Россиянең иң матур шәһәрләре: Бөек Новгород, Түбән Новгород, Архангельск, Сочи, Волгоград турында кыскача сөйли белү, диалоглар төзү |
| 66–67 | Туган җиребез – Татарстан. *Исем + тартымлы исем* төзелмәсе: *Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре* | Татарстанның мәйданы, халкы, башкаласы турында кыскача белешмә бирә белү |
| 68–71 | Татарстанның шәһәрләре, аларның истәлекле урыннары | Татарстан шәһәрләренең тарихи истәлекләре, үзенчәлекләре турында кыскача сөйли белү. Диалоглар төзү |
| 72–74 | Кремльгә экскурсия | Казан Кремленең тарихи истәлекләре турында диалоглар төзи, кыскача сөйли белү |
| 75–77 | Казан – театрлар, музейлар шәһәре. Казан – бөек шәхесләр шәһәре | Казан театрларын, музейларын, Казанда яшәгән бөек шәхесләрне атый белү, диалоглар төзеп сөйләшә белү |
| **Музыка дөньясында (13 сәгать)<br>III. Мир моих увлечений** | | |
| 78–80 | Татар музыка сәнгате классиклары – аталы-уллы Яруллиннар. Фәрит Яруллин – беренче татар балеты авторы | Татар музыка сәнгатенә нигез салучы күренекле композиторларның исемнәрен атый белү, диалоглар төзеп сөйләшү |
| 81–83 | Татарстанның халык артисты, композитор Салих Сәйдәшев. Совет Армиясе маршы. Без хикәя язабыз | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген кыскача сөйли белү. Тексттагы мәгълүматны аңлый, кирәклесен аерып ала белү. Эчтәлек нигезендә үзара сөйләшә белү |
| 84–86 | Татар халкының күренекле композиторы Нәҗип Җиһанов. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры | Татар халкының күренекле композиторы Нәҗип Җиһанов турында кыскача белешмә бирә белү. Татар музыка сәнгатендә аның хезмәтен күрсәтә белү. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры ачылу тарихы, репертуары турында диалоглар төзеп сөйләшү |
| 87–88 | Татар халкының яраткан җырчысы Әлфия Авзалова | Әлфия Авзалованы «Моң патшабикәсе» булуын әйтә, раслый белү. Татар музыка сәнгатендә аның хезмәтен күрсәтә белү |

| | | |
|---|---|---|
| 89–90 | Россиянең, Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров | Россиянең, Татарстанның халык артисты Илһам Шакировның биографиясен сөйли белү. Татар музыка сәнгатендә аның хезмәте турында сөйли белү |
| **Табигать һәм кеше (12 сәгать)**<br>**II. Мир вокруг меня** | | |
| 91–92 | «Табигать» текстына караган лексик-грамматик материал.<br>Табигать – безнең әйләнә-тирәбез.<br>Кушма җөмләләрдә сүз тәртибе | Тексттагы мәгълүматны аңлый, кирәклесен аерып ала белү. Эчтәлек нигезендә үзара сөйләшә белү |
| 93–94 | Нәрсә ул табигать?<br>Без – табигать балалары.<br>Табигатьне пычратучыларга каршы көрәшү – һәркемнең изге бурычы.<br>Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Баш кисәкләр арасында сызык куелу очрагы | Табигатьнең кешегә файдасы, табигатькә зарар китерү, кешелекнең нинди куркыныч алдында торуы, ни өчен табигатьне сакларга кирәклеге турында сөйләшү |
| 95–96 | Теләк фигыль.<br>Теләк белдерү формаларының сөйләмдә кулланылышы | Теләк фигыльне кулланып, урманга, елга буена барырга теләк белдерү. Табигатьнең чисталыгы өчен көрәшергә чакыру |
| 97–98 | Теркәгечләр. Тезүче һәм иярүче теркәгечләр | Тезүче һәм иярүче теркәгечләр кулланып, табигатькә сакчыл караш турында җөмләләр төзеп сөйләшү |
| 99–100 | «Урман» текстына караган лексик-грамматик материал.<br>Урман – кешенең якын дусты | Текстны сәнгатьле уку.<br>Төп фикерне саклап, текстны сөйләргә өйрәнү. Урманның файдасы, матурлыгы турында диалоглар төзү |
| 101–102 | Табигатьне саклау – һәркемнең изге бурычы | Татарстан табигате, байлыклары, киләчәге турында әңгәмә кору.<br>Табигатьне саклау – һәркемнең изге бурычы икәнен дәлилләп сөйли белү |

## Ишетеп аңлау күнегүләре

### Күп укыган күп белер

### 1–4 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
Мәктәп, такта, дәфтәр, дуслар, дәреслек, бәйрәм, китап, бүген, иртәгә.

**2. Прослушайте и добавьте к каждому существительному соответствующее прилагательное.**
Укытучы, каникул, укучы, дәреслек, дуслар, күлмәк.

**3. Прослушайте и повторите слова, добавляя к каждому местоимение *минем*.**
Мәктәп, укытучы, дус, дәреслек, китап, шатлык.

**4. Прослушайте и укажите двусложные слова.**
Укый, көтә, җитәкче, укытучы, дус, яңа, чиста, утыра.

**5. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Мин мәктәпкә ... . 2) Мин яңа дәфтәрләр ... . 3) Мин дәфтәремне өйдә ... . 4) Мин бүген бишле ... . 5) Мин дусларым белән ... .

### 5–6 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Укучылар мәктәпкә киләләр.
   Укучылар сентябрьдә мәктәпкә киләләр.
2) Быел бездә яңа сыйныф җитәкчесе.
   Быел бездә яңа сыйныф җитәкчесе булачак.

**2. Прослушайте и скажите, что опущено во втором предложении каждой пары.**

1) Көз җиткәч, без мәктәпкә килдек.
   Без мәктәпкә килдек.

2) Укытучы безгә дәреслек тарата.
Укытучы дәреслек тарата.
3) Сыйныфка яңа укучы килде.
Сыйныфка укучы килде.
4) Без быел химия фәне өйрәнәбез.
Без химия фәне өйрәнәбез.
5) Татар теле дәресләре 249 нчы кабинетта була.
Дәресләр 249 нчы кабинетта була.

**3. Прослушайте предложения и поставьте к ним вопросы.**

1) Балалар мәктәпкә килделәр. 2) Әлфиягә татар теле дәресе ошый. 3) Маратның дәреслеге чиста. 4) Мәктәптә укучыларга рәхәт. 5) Татар теле кабинеты чиста, якты.

**4. Прослушайте предложения и скажите, как изменились бы предложения, если бы действия не происходили.**

1) Укулар сентябрьдә башлана. 2) Без быел яңа фән өйрәнәбез. 3) Безнең сыйныфка 2 яңа укучы килгән. 4) Җәйге каникулдан соң без мәктәпкә киләбез. 5) Дәресләр 219 нчы кабинетта үтә.

**5. Прослушайте текст и расскажите содержание.**

Менә яңа уку елы башланды. Без мәктәпкә килдек. Безнең сыйныфка 2 яңа укучы килгән. Кабинетлар 2 нче катта урнашкан. Без 2 нче сменада укыйбыз.

**6. Прослушайте диалог и расскажите содержание.**

– Гөлназ, син кайда укыйсың?
– Мин 55 нче мәктәптә укыйм.
– Ничек укыйсың?
– Яхшы.
– Сиңа нинди фәннәр ошый?
– Мин тарих һәм география белән кызыксынам.
– Бу фәннәр сиңа ошыймы?
– Әйе, бик ошый.

## 7–8 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите глаголы прошедшего неочевидного времени.**

Уйлаган, киткән, барды, күргәнсең, язганбыз, утырдым, килгәннәр, оныткан, аңлыйбыз.

**2. Прослушайте и скажите, как изменились бы аффиксы глаголов, если бы действия не происходили.**

Уйлаган, яраткансың, әзерләгәннәр, ашаган, йоклап киткәнмен, ашагансыз, калдырганбыз.

**3. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Ул дәресләрне әзерләргә утырды.
   Ул дәресләрне әзерләргә утырган.
2) Син мин яраткан ашны пешердең.
   Син мин яраткан ашны пешергәнсең.
3) Мин бик тиз йоклап киттем.
   Мин бик тиз йоклап киткәнмен.
4) Сез яхшы уйнадыгыз һәм җиңдегез.
   Сез яхшы уйнагансыз һәм җиңгәнсез.

**4. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Мин дәрес әзерләргә ... . 2) Мин ишетмәдем, әни эштән ... . 3) 8 нче сыйныф укучылары татар теленнән диктант ... . 4) Син ял көне кинога ... . 5) Алёша яхшы китап ... .

## 9–10 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с твёрдыми согласными.**

Әзерләрсең, ашарбыз, башлаячакбыз, уянырлар, күчерәчәксез, сөйләрләр, кайтырбыз.

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

Барачак, килерләр, өлгерермен, китәчәксең, кайтты, уйнарсыз.

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них подходящие местоимения: *мин, син, ул, алар.***

Уйнаячаклар, чишәрсең, әзерләнер, күчерермен, утырырмын, китәрләр, барачаксың, эшләячәксең.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишләр?***

Кайталар, килер, күчерерсең, әзерләнер, баралар, эшләр, өлгерерсез, чишәр.

**5. Прослушайте и измените слова по образцу.**

Образец: *кайта – кайтачак – кайтыр.*

Күчерә, чишә, әзерләнә, эшли, өлгерә, уяна, сөйли, сорый.

**6. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Иртән бик иртә ... . 2) Мәктәпкә баргач, Сашадан мәсьәләне ... . 3) Мин мисалны үзем ... . 4) Укытучы икеле куймаса, иртәгә ... . 5) Мәктәптән соң озак телевизор ... .

## 11–13 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите деепричастия.**

Кайтам, барам, кайткач, ашады, ашыгып, ашыга-ашыга, өлгермәде, йоклады, йоклагач, ял итте, ял итә-итә, караңгы төште, кайтты, караңгы төшкәч, башланды, чәй эчә-эчә.

**2. Прослушайте и продолжите предложения.**

1. Алёна бик тырышып укыгач, яхшы ... .
2. Ул стадионга барганчы, дәресләрен ... .
3. Ул мәктәптән шатланып кайтты, чөнки ... .
4. Настя өйгә йөгерә-йөгерә кайтты, чөнки ... .
5. Ул уйлый-уйлый арыды, ләкин эшне ... .

**3. Прослушайте и укажите аналитические глаголы, выражающие завершённость действия.**

Сөйли башлый, сөйли башлады, торып китте, ашап утыра, ашап бетерде, карый башлады, карап бетерде.

**4. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Дәрес әзерләргәч, стадионга киләм.
   Бераз ял иткәч, стадионга киләм.
2) Дәрес әзерләргә кино карагач өлгерермен.
   Дәрес әзерләргә стадионнан кайткач өлгерермен.
3) Дәресләрне иртәгә әзерләрмен.
   Дәресләрне иртәгә иртән әзерләрмен.
4) Ашыйм, аннан соң хоккей уйнарга китәм.
   Ашыйм, аннан соң дәрес әзерлим.

**5. Прослушайте диалог и расскажите содержание.**

– Марат, әйдә, өйгә кайтканчы, хоккей уйнарга барабыз.

– Өлгерербез әле. Минемчә, башта өйгә кайтып ашыйк, аннан соң барырбыз

– Дөрес сүз. Син миңа шалтыратырсың, ярыймы?

– Килештек.

## 14–15 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә] и переведите.**

Килсәм, китмәсәң, барсалар, кайтмасаң, әзерләсәгез, чишсәм, сөйләсә.

**2. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Килсәм, китмәсәң, әзерләсәгез, чишсәм, ял итсә, сөйлим.

**3. Прослушайте и измените слова по образцу.**

Образец: *кайта – кайтса – кайтмаса.*

Йоклый, әзерли, ял итә, уяна, сөйли, уйный, ашый, килә, кычкыра.

**4. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них подходящие местоимения *мин, син, ул, алар*.**

Йокласаң, әзерләсәм, ял итсәләр, уянса, күчермәсәм, сөйләмәсәләр, уйнамасаң, ашасаң, чишсә, куймаса.

**5. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Бүген иртә уянсам, ... . 2) Мәктәпкә алдан килсәм, ... . 3) Укытучы миннән сорамаса, ... . 4) Бу кагыйдәне белсәм, ... . 5) Бүген икеле алмасам, ... .

## 16–18 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, состоящие из одного слога.**

Аш, дәрес, эш, кич, ял, йокы, иртә, иртән, көн, өлгерә, әле, инде.

**2. Прослушайте слова и задайте к ним вопросы.**

Мәктәптән, дәресләрне, хоккей, ашаячак, башланды, уйнаячак, өлгерәм, әзерләргә, эшлим.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Кайтырга, футбол, ашарга, сөйләргә, эшләргә, эчәргә, әзерләргә.

**4. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Дәрес әзерләргә өлгерермен.
   Дәрес әзерләргә кино карагач өлгерермен.
2) Наил дәрес әзерләячәк.
   Наил бүген дәрес әзерләячәк.
3) Дәресләрне иртәгә әзерләрмен.
   Дәресләрне иртәгә иртән әзерләрмен.

**5. Прослушайте диалог и расскажите содержание.**

– Марат, әйдә хоккей уйнарга барабыз.
– Дәрес әзерлисем бар.
– Өлгерерсең әле, башта ял итәргә кирәк.
– Дөрес сүз. Кичкә кадәр биш тапкыр әзерләп була әле.

**6. Прослушайте и закончите диалог.**

– Марат, чәй эч тә, дәресләреңне әзерлә.
– Мультфильм гына карыйм да әзерли башлыйм.
– Математикадан контроль эш кайчан була?
– ... .

## 19–22 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с мягким произношением.**
Иртән, күчерермен, вакыт, мәзәк, дәрес, чакыра, сорый, өй, кичә.

**2. Подберите антонимы к следующим словам.**
Җылы, тиз, иртә, кичә, кызык, ялкау.

**3. Прослушайте и продолжите предложения.**

Кояш бата, ай ...,
Барый йокларга ...,
Иртәгесен сумкасына
Икеле ... ... .
«Нәрсә карый бу Барый?» – дип,
Бөтен ... ... .

**4. Прослушайте диалог и расскажите содержание.**

– Азат, син бүген кайчан уяндың?
– Ни өчен сорыйсың, Настя?
– Мин бүген иртә уяндым.
– Ә мин, киресенчә, соң уяндым.
– Мәктәпкә соңга калмадыңмы?
– Калдым шул, 10 минутка соңга калдым.

**5. Прослушайте и перескажите текст.**

Наил дустына керде. Дусты диванда йоклап ята иде. Ул Наилне уятты. Алар хоккей уйнарга йөгерделәр. Анда дуслары күп иде. Алар кич буе хоккей уйнадылар, соң гына өйгә кайттылар. Әниләре балаларны ачуланды. Малайлар дәрес әзерләргә утырдылар.

**6. Прослушайте и скажите, согласны ли вы с этими утверждениями.**

1) Наил иртән иртәрәк уянды, ләкин тормады.
2) Наил иртән иртәрәк уянды һәм торды.
3) Наил иртән иртәрәк уянды һәм дәресләрен әзерләде.
4) Наил иртән иртәрәк уянды, ләкин дәресләрен әзерләмәде.
5) Наил: «Өй эшен, мәктәпкә баргач, үзем эшләрмен», – дип уйлады.
6) Наил: «Өй эшен, мәктәпкә килгәч, Наилдән күчерермен», – дип уйлады.

## 23–26 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

Мәһдиев, язучы, һәм, галим, Арча, Гөберчәк, авыл, әсәрләр, яңалык, хәзер, дәүләт, безнең, арада.

**2. Прослушайте и повторите слова, добавляя к каждому окончание прошедшего времени.**

Кача, сорый, бутала, сыза, тирли, сөйли, әйтә, харап була, ышана, белә, ярата.

**3. Прослушайте и укажите двусложные слова.**

Арча, училище, институт, тәмамлый, җиңел, астына, сызык, хәбәр, басым, сызык, русча, сөйли.

**4. Прослушайте и переведите.**

Шул, ул, бу, болар, соң, менә, үзе, күп, аз, башта, аннан соң.

**5. Прослушайте и назовите правильное утверждение.**

1) Гыйззәтуллин рус теле дәресендә харап булды.
   Гыйззәтуллин биология дәресендә харап булды.
2) Гыйззәтуллин: «Карим опоздал на урок», – дип дөрес әйтте.
   Гыйззәтуллин: «Карим опоздал на урок», – дип дөрес әйтмәде.
3) Гыйззәтуллин «урок» сүзенә басымны дөрес куйды.
   Гыйззәтуллин «урок» сүзенә басымны дөрес куймады.
4) Ул «урок» сүзендә басымны икенче иҗеккә куйды.

Ул «урок» сүзендә басымны беренче иҗеккә куйды.

**6. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Дүрт дәрестән соң педучилищедан ... .
2) Гыйззәтуллин рус теле дәресендә ялгышты, басымны ... .
3) Иянең астына бер сызык, хәбәргә ике сызык ... .
4) Гыйззәтуллин «урок» сүзендәге басымны ... .
5) Әгәр училищены тәмамлаганчы миндә укысаң, син барыбер русчаны ... .
6) Гыйззәтуллин училищедан ... .

## 27–30 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите глаголы прошедшего неочевидного времени.**

Туа, киткән, килә, уйлаган, киткән, оныткан, күрә, омтыла, утыра, тәмамлый.

**2. Прослушайте и скажите, как изменились бы аффиксы глаголов, если бы действия не происходили.**

Туа, киткән, килә, уйлаган, киткән, оныткан, күрә, омтыла, утыра, тәмамлый.

**3. Прослушайте и переведите словосочетания.**

Яшь вакыт, үлем хәбәре, урта мәктәп, урын өстендә, бәхетсез язмыш, иҗат итә.

**4. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Фәнискә 4 яшь вакытта әтисе фронтка китә.
   Фәнискә 4 яшь вакытта әтисе фронтка китә, тиздән аның үлем хәбәре килә.
2) Армиядә ул спорт белән шөгыльләнә.
   Армиядә ул спорт белән шөгыльләнә, киләчәк турында хыяллана.
3) Ул, турникта әйләнгәндә егылып төшә.
   Ул, турникта әйләнгәндә егылып төшеп, умыртка сөяген имгәтә.
4) Фәнис Яруллин читтән торып Казан дәүләт университетын тәмамлый.
   Фәнис Яруллин читтән торып Казан дәүләт университетын тәмамлый, хикәяләр, шигырьләр иҗат итә башлый.

## Яшьтәшләр белән аралашу

## 31–32 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с мягким произношением.**

Берәүләр, рәнҗү, искечә, дуслар, аралашу, фикер алышу, бәхәсләшү, кагыйдә, үрнәк, фикер, тупас, таза, оялу, гаеп, киңәш.

**2. Прослушайте и переведите.**
Кайбер, берәүләр, кайберәүләр, кайберсе.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**
Тупас, тәрбияле, озын буйлы, оялчан, дуслаша, матур.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишләсә?***
Дуслаша, дус булса, оялса, әйтә, укый, аралашса, җырламый, яши, уйламый.

**5. Прослушайте и укажите слова, обозначающие характер человека.**
Ябык, таза, киң күңелле, тәрбияле, әдәпле, кечкенә, тупас, олы, киң җилкәле.

**6. Прослушайте диалог и расскажите содержание.**
– Надя, миңа бер егет ошый.
– Настя, нинди егет ул?
– Ул бик әдәпле, тупас түгел.
– Буе нинди?
– Уртача буйлы, кара чәчле.

**7. Прослушайте и измените по образцу.**
О б р а з е ц : *уйнарга – уйнау.*
Пешерергә, сатарга, өйрәнергә, эшләргә, белергә, бәяләргә.

## 33–36 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
Мәктәп, әдәпсез, кешеләр, тәрбияле, кимчелек, бәлки, әдәпле, тупас.

**2. Прослушайте и измените слова по образцу.**
О б р а з е ц : *яраталар – яратам – яратмыйм.*
Көләләр, оялалар, уйныйлар, дуслашалар, аралашалар.

**3. Прослушайте и скажите, согласны ли вы с этими утверждениями.**
